Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының бишенче чакырылышының сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

21 май, 2026 ел № 60

Питрәч авылы

2025 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында

Татарстан Республикасы кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Питрәч муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе мәгълүматын тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турындагы мәгълүматны 2025 елда игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, барлык милек рәвешләрендәге учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә эшендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе мәгълүматын исәпкә алуны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозу очракларына юл куймау буенча оператив чаралар күрүне, халыкны хокукый агартуга юнәлдерелгән чараларны активрак үткәрүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов